СОВЕТ КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

24.10.2017　　　　　　　　　　　　28-129

с. Куралово

Учаклар ягу урыннарын һәм ысулларын билгеләү, чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 2012 елның 25 апрелендәге «Янгынга каршы режим турында» 390 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге территориясендә торак пунктларның янгынга каршы тотрыклылыгын арттыру максатларында,

Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегендә учак ягу, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне, якындагы корылмаларга кадәр ара 50 метрдан да ким булмаган урыннарда, җилсез көннәрдә һәм чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яндыруны даими тикшереп тору шартыннан тыш яндыру тыела.

2. Әлеге карар җирлек территориясендә махсус янгынга каршы режим кертү чорында үз көченә керми.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　Л.И.Коткова